**Сыйныф :** 1А (татар төркеме)

**Сәгать саны:** 33 сәгать, атнага 1 сәгать.

”Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”

1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф”

нәшрияты, 2011ел.

**Дәреслек:** - Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова Әлифба: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.-

Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әдәби уку: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016.

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1.Программа: “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011)

2 . Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында гомуми башлангыч белем бирү программасы.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2018 ел)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар”буенча 1 нче сыйныфлар өчен әдәби укуны укытуга 64 сәгать каралган. Мәктәпнең еллык календарь укыту графигы буенча 1 нче сыйныфларда 33 атна булу сәбәпле, эш программасы белем бирү учреждениесенең 2017 -2018 елга гамәлдәге базис планы буенча атнага 1 сәгать исәбеннән 33 сәгатькә төзелә. Эш программасында, барлык өйрәнелә торган темалар сакланып, сәгатьләр санына үзгәрешләр кертелде. Бу үзгәрешләр программаның эчтәлегендә күрсәтелә. 1 нче сыйныф өчен әзерләнгән эш программасының эчтәлеген мәктәптә үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр тәшкил итә

## <u>Укытуның планлаштырыла торган нәтиҗәләре.</u>

Әдәби уку буенча төзелгән эш программасы башлангыч сыйныф укучыларының **шәхси** үсеш-үзгәреш, **предметара** һәм **предмет** нәтиҗәләрен үзләштерүне күз алдында тота.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләренә** ирешү осталыгы булып түбәндәгеләр санала:

-гомуми кулланыш нормалары һәм кыйммәтләре күзлегеннән кешеләрнең эш-гамәлләрен, тормыш ситуцаияләрен бәяләү;

-текстны “эмоциональ кичерү”, үз фикереңне белдерү;

-укылган әсәр геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү.

**Предметара нәтиҗәләр** булып әдәби уку буенча универсаль уку гамәлләре формалашу санала (УУГ).

| **Шәхси универсаль уку гамәлләре.** | **Регулятив универсаль уку гамәлләре.** | **Танып-белү универсаль уку гамәлләре.** | **Коммуникатив универсаль уку гамәлләре.** |
|---|---|---|---|
| 1.Түбәндәге кыймматләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык,түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.<br>2.Укучы ролен үзләштерү. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.<br>3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү. | 1.Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оештыру.<br>2.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.<br>3.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү планын билгеләү. | 1.Китап белән эшләү: бирелгән бүлекне өйрәнгәндә формалашучы белем-күнекмәләрне билгеләү.<br>2.Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу.<br>3.Геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу.<br>4.Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү. | 1.Дәрестә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.<br>2.Укытучы, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү.<br>3.Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшү, хушлашу,рәхмәт белдерү;<br>4.Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.<br>5. Парлап һәм күмәк эшләү. |

**Предмет нәтиҗәләре:**
-укытучы, укучы укыган текстны ишетеп аңлау;
-бөтен сүзләрне аңлап, дөрес уку;
-текстны тулысынча сөйләү;
-кечкенә күләмле шигырьләрне ятлау;
-рәсем буенча телдән хикәя төзү;
-автор,текст исеме һәм текстның эчтәлеген билгеләү;
-хикәя , шигырьне аера белү.

**Әзерлек чоры ахырына укучылар:**

- элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны аңлый, шулай ук татар алфавитының басма хәрефләр системасын атый һәм формалары буенча аера белергә;
- рәсем, график модель, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2-4 сүздән торган җөмләләр һәм 3-4 җөмләдән торган хикәя төзи; парта артында дөрес утыра һәм уку әсбапларыннан дөрес файдалан белергә тиешләр.

Әлифба чорының ахырына укучылар:

1) - татар теле авазларының җырлана торган сузык аваз һәм җырланмый торган тартык аваз; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала, ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә-калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен, сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;

- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар яки хәрефләр белән белдерүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтне белдерүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен аңлый белергә тиеш.

2) укучылар сүз башыннан башлап, андагы һәр авазны көчлерәк итеп билгели бара, берсен аерып алып, аңа характеристика бирә;

- анализ вакытында тартыкларның яңгыраулыгын- саңгыраулыгын билгеләү алымнарын куллана;

- сүзне иҗекләргә бүлә;

-схемалардан сүзнең аваз язылышын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп укый белергә тиеш.

Грамотага өйрәтүнең йомгаклау чорында:

- туган телнең сөйләм төзелешен аңлый, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст кебек тел берәмлекләрен образлы күзаллый;
- татар алфавиты басма һәм язма хәрефләренең график системасын;
- һәр хәрефнең элементларын;
- һәр укучы, үзенә генә хас темпта, басма һәм язма текстларны орфоэпик нормаларга туры китереп укый;
- текстның аерым бер өлешләрен сөйли;
- тыңланган текстка исем кушарга өйрәнергә тиешләр.

Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре” юнәлеше буенча укучы өйрәнәчәк:

- фольклор әсәрләрен (такмак, җыр, санамыш, табышмак, мәкаль, әйтем, әкият) аңлап зиһенгә кабул итә һәм аера белергә;
- төрле жанрдагы (хикәя, шигырь, әкият) әсәрләрне кычкырып укырга һәм эчтәлек буенча сорауларга җавап бирергә;
- -әдәби әсәрләрне дөрес итеп әйтергә (авторның исем- фамилиясе, әсәрнең исеме);
- китап тышлыгын модельләштерергә:авторын, исемен, жанрын һәм темасын (туган ил, балалар, хайваннар, табигать турында).

Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:

-укылган әсәрнең әхлакый эчтәлеген аңларга;
әсәр һәм геройлар турында фикерләрен җиткерергә;
әсәр өзекләреннән укылган әсәрләрне танырга.

“Әдәби пропедевтика”юнәлеше буенча
укучы өйрәнәчәк:

- өйрәнелә торган әсәрләрнең жанрларын һәм темаларын билгеләргә һәм әйтергә;
- сөйләмдә әдәби төшенчәләрне (әдәби әсәр, авторның исеме һәм фамилиясен, әсәрнең исемен кулланырга);
- шигырь, хикәя, табышмак, мәкаль, әкият жанрларын аерырга;
- халык һәм автор әкиятләрен үзенәлекләре буенча аерырга.

укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:

- әкият һәм шигырь, табышмак һәм мәкаль текстларын чагыштырырга;
- тексттан чагыштырулар, эндәшләрне табарга;
- тексттан геройлар арасындагы диалогны табып укыргарәсеме һәм тышлыгы буена китапның якынча темасын билгеләргә.

“Иҗади эшчәнлек” юнәлеше буенча укучы өйрәнәчәк:

- диалог формасындагы кечкенә әсәрләрне рольләргә бүленеп укырга;
- укылган әсәр геройлары белән төрле ваеыйгалар уйларга;
- герой яки үз исеменнән әсәр эчтәлеген сөйләргә.

укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак:

- укылган әсәрнең аерым эпизодларына рәсем ясарга;
- аерым эпизодларны парлап яки төркемләп сәхнәләштерергә
- телдән кечкенә хикәя, әкият уйларга

**<u>1 нче сыйныф өчен “Әдәби уку” курсының эчтәлеге</u>**

**Программада 33 сәгать каралган:**

| № | Төп темалар | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Телдән әзерлек чоры | 4 |
| 2 | Әлифба чоры | 18 |
| 3 | Әлифбадан соңгы чор. Уку | 11 |
| | Барлыгы | 33 |

## Календарь- тематик планлаштыру

| № | Дәреснең темасы | Эчтәлек элементлары | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Планда | Факт |
| 1 | Рәсем буенча хикәя төзу Таныш булыйк! | “Әлифба” дәреслеге, аның авторлары, рәссамы белән таныштыру. Әлифба дәреслеге белән эшләргә, укыганда дөрес утыру кагыйдәләрен үтәргә өйрәнү. Укучыларда “әйтмә” һәм “язма” сөйләм турында башлангыч белем формалаштыру. Шартлы билгеләр белән таныштыру, аларның мәгънәләрен аңлату. Сөйләм этикеты (исәнләшү, саубуллашу, аралашу, танышу) нормалары белән танышу. Танышу сүзләрен үзләштерү. “Әйтмә” һәм “язма” сөйләмне аерырга, сөйләм этикеты нормаларында өйрәнү. Сөйләмдә итагатьле сүзләр куллана белү. | 3.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Аралашу.<br>Җөмлә<br>Текст. “Иң күңелле көн”<br>Син әкиятләр беләсеңме?<br>Бәйләнешле сөйләм. | Аралашу ни өчен кирәк? Без кем белән ничек аралашабыз? Аралашу төрләрен аңлату.<br>Аралашканда “тылсымлы” сүзләр кулланырырга өйрәтү.<br>Җөмлә турында белешмә бирү. Әйтмә сөйләм һәм җөмлә схемалары белән таныштыру. Рәсемнәр буенча җөмләләр төзү күнекмәләрен формалштыру.<br>Татар телендә җөмләдәге сүз тәртибен аңлату. Сорауларга җавап бирү.<br>Сөйләмнән җөмләләрне аерып алырга өйрәнү. Сүз һәм җөмлә аермасын аңларга өйрәнү. Сөйләм этикеты нормалары белән танышу.<br>Татар телендә танышу, хушлашу сүзләрен үзләштерү.<br>Текст турында белешмә бирү. Текст моделе белән таныштыру. | 10.09 | |
| 3 | Спорт мәйданчыгында. Предмет белдерүче сүзләр. Гаилә.<br>Сөйләм.Шәһәрдә.<br>Билге белдерүче сүзләр. | Текст турында белешмә бирү. Текст моделен үзләштеренү камилләштерү. Предметны белдерүче сүзләрне ныгыту. Сүз моделен аңлату. Текст эчтәлеген тыңлау, рәсем белән эчтәлекне тәңгәлләштерү. Текст турынд белешмә бирү. Тексттан җөмләләрне аерып алу, предметны белдергән сүзләрне таба белү күнекмәләрен ныгыту. Предметны белдергән сүзләрне гомумиләштереп әйтү. Бәйләнешле сөйләм турында белемнәрне ныгыту. Фонематик ишетеп аңлау күнекмәләре булдыру. Хәрәкәтне белдерүче сүзләр белән таныштыру. Гаилә әгъаларын белдергән кеше исемнәрен атый, хәрәкәт белдерүче сүзләрне табып әйтә белергә өйрәнү. Шәһәр тормышына караган тамаларны әйтә белү Сөйләм (ныгыту). Сүрәтләү хикәясе төзү күнекмәләре булдыру. Билге белдерүче сүзләр белән танышу.Укучыларның актив сүзлек запасын баету. Юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү | 17.09 | |
| 4 | Сөйләм авазлары.<br>Сузык һәм тартык авазлар | Сузык һәм тартык авазлар турында мәгълүмәт бирү. Сүзнең беренче авызын тавыш белән аерып күрсәтү.<br>Сузык һәм тартык авазлар арасындагы аерманы аңлату.<br>Йорт хайваннары һәм кошлары турында белешмә | 24.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | бирү.Игътибарлылык сөйләм телен һәм фонематик ишетеп аңлауны үстерү | | |
| 5 | Сузык [а],[ә] авазлары һәм хәрефләре. Сузык [ы],[ э] авазлары һәм хәрефләре | [а],[ә], [ы], [э], авазы һәм хәрефе белән танышу, фонематик ишетеп аңлау күнекмәсен, тыңлыйһәм ишетә белүне үстерү. Сүзне иҗекләргә бүлү күнекмәләрен аңлату. Авазны әйтергә, сүзгә аваз анализы ясарга, сүзне иҗекләргә бүлергә,өйрәнелә торган авазның сүздәге урынын билгеләргә, авазга билге булып килгән баш һәм юл хәрефләрен танырга өйрәнү. | 1.10 | |
| 6 | Сузык [и],[у], [ү] авазлары һәм хәрефләре Сузык [ө], [о] авазлары һәм хәрефләре | фонематик ишетеп аңлау, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерү. Сүзне иҗекләргә бүлү ысулларын ныгыту. Сюжетлы рәсем буенча текст төзергә, өйрәнелә торган авазны табарга, сүзгә аваз анализы ясарга, тексттан өйрәнелә торган авазны ишетеп танырга. Шул аваз кергән сүзләр уйлап әйтергә өйрәнү. Э хәрефенең ике авазга билге булып килүен төшендерү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү авазны ишетеп тану, сүзгә аваз анализы ясау күнекмәләрен үстерү, логик фикерләү формалаштыру. | 8.10 | |
| 7 | [н], [л] авазлары һәм Н, н, Л, л хәрефләре. | Сузык һәм тартык аваз арасындагы аерманы ачыклау. Тартык [н]авазы һәм Н,н хәрефләре белән таныштыру.Дөрес уку күнекмәләре формлаштыру. Тартык [н] авазына яңгырау,калын,нечкә аваз буларак характеристика бирергә, авзның сүздәге урынын билгеләргә, кушлмалар,иҗекләр,сүзләр укырга, бәйлнешле сөйләм төзергә,текстны тыңлап аңларга өйрәнү. Тартык [л]авазы һәм Л,л хәрефләре белән таныштыру, фикерне төгәл һәм дөрес | 15.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | формалаштырырга өйрәтү,<br>сүзне “үстерү” һәм “үзгәтү”<br>алымнары белән танышу.<br>[л]авазын аерып алырга,<br>сузык аваз белән аермасын<br>аңлатырга, авазның калын,<br>нечкә яңгырашына сузык<br>авазларның йогынтысын<br>ачыкларга,сүзләрне<br>үзгәртергә,мәгънәләрен<br>ачыкларга өйрәнү | | |
| 8 | [м],<br>[р]<br>авазлары һәм<br>М, м, Р, р<br>хәрефләре. | [м] авазы һәм М, м хәрефәре<br>белән таныштыру,<br>укучыларның актив сүзлек<br>баету, уку күнекмәләрен<br>формалаштыру.<br>Рәсем буенча сүрәтләү<br>хикәясе төзергә, [м] авазы<br>кергән сүзләрне табып<br>әйтергә, сүзләр янындагы<br>шартлы билгеләрне, ачы,<br>ябык иҗекләрне, сүзләрне,<br>җөмләләрне укырга өйрәнү.<br>[р] авазы һәм Р, р хәрефләре<br>белән танышу, [р] авазы<br>кергән сүзләрне уку.<br>Укучыларда туган як<br>табигатенә карата мәхәббәт<br>тәрбияләү.<br>Кошларны танып белергә,<br>сүзгә аваз анализы ясарга,<br>тексттан р хрефе кергән<br>сүзләрне табарга,<br>бәйләнешле текст төзергә,<br>фикереңне дөрес, төгәл әйтеп<br>бирергә өйрәнү | 22.10 | |
| 9 | [й], [ң]<br>авазлары һәм<br>Й, й, ң<br>хәрефләре | [й] авазы һәм Й, й хәрефләре<br>белән таныштыру. Логик<br>фикерләүне үстерү.<br>Сүзләрне, җөмләләрне уку<br>күнекмәләрен каилләштерү.<br>Бәйләнешле сөйләм теелен<br>үстерүю.Фикерне төгәл,<br>дөрес, эзлекле итеп әйтергә,<br>аваларны дөрес әйтеп<br>укырга, сорауларга җавап<br>бирергә, укытучы биргән<br>биремнәрне үтәргә, сүз<br>эченнән яңа сүзләр табарга<br>өйрнү.<br>[ң] авазы, ң хәрефе белән таныштыру. Уку<br>һәм сөйләм | 29.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | күнекмәләрен ныгыту.<br>Ң хәрефнең баш хәрефе юклыгын аңларга, текстлар ятларга, үз фикерләрен әйтергә өйрәнү. | | |
| 10 | [йа],<br>[йә]<br>авазлары һәм<br>Я,<br>я<br>хәрефләре. | Я хәрефе белән таныштыру.Я хәрефенең ике аваз кушылмасына[йа], [йә] билге булып йөрүен төшендерү, калын яңгырашлы сүзләрдә [йа], нечкә яңгырашлы сүзләрдә [йә] кушылмасы булып укылуын аңлату.<br>Я хәрефен калын яңгырашлы сүзләрдә [йә] дип укырга, бер авазы белән генә аерылып торган, бер авазга артык булган сүзләрне укырга өйрәнү.Предметны,билгене белдеүче сүзләрне табу. | 12.11 | |
| 11 | [йу],<br>[йү],[йы], [йэ]<br>авазлары һәм<br>Ю, ю, Е, е<br>хәрефләре. | Ю хәрефе белән таныштыру.<br>Ю хәрефенең ике аваз кушылмасына [йу], [йү] билге булып йөрүен төшендерү, калын яңгырашлы сүзләрдә [йу], нечкә яңгырашлы сүзләрдә [йү] кушылмасы булып укылуын аңлату.<br>Кечкенә күләмле әкиятләрнең эчтәлеген сөйләргә, ю хәрефен танып укырга, билгеләр буенча табышмакның җавабын табарга, мәкаль эчтәлеген аңларга өйрәнү. | 19.11 | |
| 12 | [г],<br>[к]<br>авазлары һәм<br>Г, г, К, к<br>хәрефләре. | [г] авазы,Г, г хәрефләре белән таныштыру. Калын яңгырашлы сүздәге аваз артикуляциясен үзләштерү, авазга харатеристика бирә белү күнекмәләрен формалаштыру ( яңгырау, калын яки нечкә, парлы), сөйләм теленүстерү, логик фикерләү һәм хәтерне үстерү.<br>Авазларны дөрес әйтергә, яңгырау тартыкларны калынлыкта, нечкәлектә чагыштырырга, текстларны | 26.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укырга, шәхси фикерен<br>әйтергә, сүзләрне,<br>текстларны орфоэпик дөрес<br>итеп укырга, гаилә турында<br>үз фикереңне әйтергә<br>өйрәнү.<br>[к] авазы, К, к хәрефләре<br>белән таныштыру. Авазларга<br>характеристика бирү<br>күнекмәләрен үстерү, дәрес<br>темасын билгели белү, логик<br>фикерләү һәм хәтер үстерү<br>өчен шартлар тудыру.<br>Авазларны дөрес әйтергә,<br>саңгырау тартыкларны<br>калынлыкта, нечтәлегә<br>чагыштырырга,  текстларны<br>укырга, шәхси фикерләрен<br>әйтергә, сүзләрне,<br>текстларны орфоэпик дөрес<br>итеп укырга, Казан шәһәре<br>турында сөйләргә өйрәнү. | | |
| 13 | в], [w], [ф]<br>авазлары һәм<br>В, в, Ф, ф хәрефләре | [в],[w] авазлары һәм В, в<br>хәрефләре белән таныштыру.<br>Авазларга характеристика бирү күнекмәләрен<br>камилләштерү, иҗекләп,<br>дөрес, сәнгатъле уку<br>күнекмәләрен<br>формалаштыруга шартлар<br>тудыру, сүзлек запасын<br>баету, туган телне өйрәнүгә<br>кызыксыну тудыру.<br>Авазлары дөрес әйтергә,<br>яңгыру тартыкны<br>калынлыкта, нечкәлектә<br>чагыштырырга, текстларны<br>укыргаөйрәнү. | 3.12 | |
| 14 | [б],<br>[п]<br>авазлары һәм<br>Б, б, П, п<br>хәрефләре. | [б] авазы һәм Б,б хәрефләре<br>белән таныштыру . Яңгырау,<br>саңгырау тартыкларны аера<br>белү, авазларга<br>характеристика бирү<br>күнекмәләрен ныгыту.<br>Укытучы биремнәрен төгәл<br>үтәү.<br>Авазларны дөрес әйтергә,<br>ягырау тартык авазны<br>калынлыкта, нечкәлектә<br>чагыштырырга , текстларны<br>укырга, шәхси фикерләрне<br>әйтергә, сүзләрне,<br>текстларны орфоэпик дөрес | 10.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | итеп укырга, куелган теа буенча үз фикереңне башкаларга җиткерергә өйрәнү.[п] авазы һәм П, п хәрефләре белән таныштыру. Текстның исемен, төп уен билгеләргә өйрәтү. Сөләм һәм уку күнекмәләрен камилләштерү.Авазларны дөрес әйтергә, саңгырау тартык авазны калынлыкта, нечкәлектә чагыштырырга текстларны укырга, шәхси фикерләрне әйтергә, сүзләрне, текстларны орфоэпик дөрес итеп укырга, куелган тема буенча үз фикереңне әйтергә өйрәнү. | | |
| 15 | [ж],<br>[ш]<br>авазлары һәм<br>Ж, ж, Ш, ш<br>хәрефләре. | [Ж],[ш]авазы һәм Ж.ж,Ш,ш хәрефләре белән таныштыру . Яңгырау, саңгырау тартыкларны аера белү, авазларга характеристика бирү күнекмәләрен ныгыту. Укытучы биремнәрен төгәл үтәү.<br>Авазларны дөрес әйтергә, ягырау тартык авазны калынлыкта, нечкәлектә чагыштырырга , текстларны укырга, шәхси фикерләрне әйтергә, сүзләрне, текстларны орфоэпик дөрес итеп укырга, куелган теа буенча үз фикереңне башкаларга җиткерергә өйрәнү. | 17..12 | |
| 16 | [җ],<br>[ч]<br>авазлары һәм<br>Җ, җ, Ч, ч<br>хәрефләре. | [җ] авазы һәм Җ, җ хәрефләре белән таныштыру. Яңгырау, саңгырау авазларны аера белү күнекмәләрен камилләштерү. Сөйләм телен үстерү. Уку күнекмәләре булдыру.<br>Авазларны дөрес әйтергә, авазны калынлыкта, нечкәлектә чагыштырырга текстларны орфоэпик дөрес итеп укырга, куелган тема буенча фикереңне белдерергә өйрәнү.<br>[ч] авазы һәм Ч, ч хәрефләре белән | 24.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | таныштыру.<br>Укучылырның хәтерен<br>үстерү, уку күнекмәләрен<br>ныгыту. Татар сөйләменә<br>кызыксыну уяту.<br>Авазларны дөрес әйтергә,<br>саңгырау тартык авазны<br>калынлыкта, нечкәлектә<br>чагыштырырга, текстларны<br>орфоэпик дөрес итеп укырга,<br>куелган тема буенча<br>әңгәмәдә катнаша белергә<br>өйрәнү. | | |
| 17 | [х],<br>[һ]<br>авазлары һәм<br>Х, х, Һ, һ<br>хәрефләре. | [х] авазы һәм Х, х хәреф<br>ләре белән таныштыру.<br>Фонематик ишетеп аңлау,<br>хәтер, игътибарлык<br>күнекмәләрен үстерү.<br>Авазларныдөрес әйтергә,<br>авазларга характеристика<br>бирергә, текстларны укырга,<br>текст белән эшләү<br>күнекмәләренә өйрәнү. [һ]<br>авазы һәм Һ, һ хәрефләре<br>белән таныштыру, авазларны<br>дөрес әйтү күнекмәләрен<br>ныгыту. | 14.01 | |
| 18 | [х],<br>[һ]<br>авазлары һәм<br>Х, х, Һ, һ<br>хәрефләре. | Дөрес уку һәм сөйләм<br>күнекмәләрен<br>камилләштерү.Авазларны<br>дөрес әйтергә, текстның төп ие турында<br>фикер йөртергә<br>өйрәнү. | 21.01 | |
| 19 | [йо],[щ],<br>[ц]<br>авазлары һәм<br>Ё.ё,Щ,щ,Ц,ц<br>хәрефләре. | Ё хәрефе белән таныштыру.<br>Бу хәреф кергән сүзләрне дөрес итеп укырга өйрәтү.<br>Казан вертолетлар һәм<br>самолетлар төзү заводлары<br>турында мәгълүмәт бирү,<br>алынма сүзләрне дөрес итеп<br>укырга өйрәнү. [щ] авазы<br>һәм Щ, щ хәрефләре белән<br>таныштыру. Текстның төп<br>уен табарга, текст буенча<br>сораулар бирергә өйрәтү.<br>Авазларны дөрес әйтергә,<br>орфоэпик дөрес итеп укырга,<br>куелган тема буенча үз<br>фикереңне әйтергә өйрәнү | 4.02 | |
| 20 | [къ],<br>[гъ]<br>авазлары һәм | Тавышсыз хәрефләр белән<br>таныштыру. Бу хәрефләрнең<br>аеру билгеләре булуын | 18.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ь,<br>ъ<br>хәрефләре. | аңлату. Фонематик ишетеп ажлау, күреп хәтергә алу күнекмәләрен үстерү. Актив сүзлек запасын баету. Ъ,ь билгеләре булган сүзләрне уку күнекмәләре булдыру. Тавышсыз ъ хәрефнең тартык авазлардан соң килгәндә калынлык билгесе булуын, ь билгесенең иҗекне нечкәртүгә юнәлгән булуын аңларга өйрәнү. | | |
| 21 | Г.Тукай “ Туган тел”.Ш.Галиев, .Вәлиева һ.б. әсәрләре “Әлифба” белән хушлашу. Алфавит. | “Әлифба” нәрсәгә өйрәткәнен искә тәшерү, мәктәп, уку турында булган шигырьләрне яттан сөйләү күнекмәләрен камилләштерү. Шигырьләрне сәнгатьле итеп өйрәнү. | 4.03 | |
| 22 | Г.Гыйльманов “Универсиада ”.Универсиад а авылы. | Универсиада турында күзалалу булдыру. Авазларны дөрес әйтергә, орфоэпик дөрес итеп укырга, куелган тема буенча үз фикереңне әйтергә өйрәнү | 11.03 | |
| 23 | Й.Шәрәпова “Икәүләшеп укыйбыз”, Р.Вәлиев “Әлифба” | Әлифба китабы белән хушлашу. | 18.03 | |
| 24 | Бала чакта алган белем-ташка язган сүз белән бер. И. Гази. “Китап” Җ. Тәрҗеманов. “Якын дус” | “Әдәби уку” дәреслеге белән танышу. И. Гази. “Китап” Җ. Тәрҗеманов. “Якын дус”. Шартлы билгеләр системасы. Дәреслекнең эчтәлеге. Сүзлекчә. Әсәрнең авторлары. | 1.04 | |
| 25 | Халык авыз иҗаты әсәрләре. *Бишек җырлары,тел шомарткычлар, такмаклар, санамышлар* . **Үзебезнең төбәктә кулланыла торган халык авыз иҗаты әсәрләре белән танышу.** | “Такмаклар”,”санамышлар, “әйтем”,“табышмак”, сүзләренә бирелгән аңлатма белән танышу. Мәкаль,бишек җырлары, бала үстергәндә әйтелә торган такмаклар, тел шомарт Кычлар, такмаклар санамышлар, әйтем,. табышмак, мәзәкләр белән танышу,төзелешләрен өйрәнү. | 8.04 | |
| 26 | *Әйтем, мәкаль, табышмак , мәзәк,* | “Әйтем”,“табышмак”, сүзләренә бирелгән аңлатма белән танышу Автор һәм халык | 15.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | *алдавыч әкиятләр* Алдавыч әкиятләр. Татар халык Әкиятләре. “Шүрәле”. | әкиятләре. Тема буенча китап күргәзмәсе. Әкиятләрнең төрләре. Әкиятнең төп уе. Әкияттәге диалоглары сәнгатьле уку. | | |
| 27 | Татар халык әкияте“Ахмак бүре” Башкорт халык әкияте “Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми? | Халык әкиятләрнең төзелешен ачыклау, эчтәлек белән танышу. Халык әкиятләренең исемлеген төзү,компьютерда эшләү. | 22.04 | |
| 28 | Хәреф миңа карап тора, мин дә карыйм хәрефкә. Дөнья үзе- укып туеп булмый торган әлифба. *“Әлифба”Г.Тукай, “Әлифбам” уфайлова , “Балалар,әйдә мәктәпкә” Дәрдемәнд “Беренчеләр” Вәлиева, “Яхшы бел” Ш.Маннур* | Бүлек исеме белән танышу.Бүлекнең эчтәлеген анализлау. Тема буенча китаплар күргүзмәсе оештыру. Г Тукай, З.Туфайлова,Дәрдемәнд, Р.Вәлиева шигырьләре. Шигырьнең темасы. Исеме. Шигырьдәге төп катнашучылар. Иҗади эш. “Мәктәптә беренче көнем” (хикәя төзү). | 29.04 | |
| 29 | *Ш.Галиев”Витаминлы хәрефләр*” Хайваннар дөньясында Ф.Тарханова”Песи-песи пескәем” шигыре. | Р.Бәшәр “Танышу”, Ш.Маннап “Ат нигә көлә?”, Й.Шәрәпова “Белми”. “Витаминлы” хәрефләр шигырьләрен уку.Сорауларга җавап бирү. Эндәшүләр. Балалар өчен иҗат иткән авторларның исемлеген төзү. Компьютерда эшләү. | 6.05 | |
| 30 | Без хайваннар һәм кошлар турында беләбезме? *Г.Тукай “Гали белән кәҗә”,* Г.Тукай “Карлыгач” *Г.Тукай “Бала белән күбәләк”,* | Р.Вәлиева “Күбәләк һәм кырмыска” Х. Халиков. “Укытучыларым”Бүлек исеме белән танышу. Бүлек эчтәлеген күзаллау.Бүлек эчтәлеген үзләштерү.Укытучы һәм укучыларның эшләрен планлаштыру. Тема буенча китап күргәзмәсе. Г.Тукай шигырьләре белән танышу. Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку. | 13.05 | |
| 31 | Без хайваннар һәм кошлар турында беләбезме? *“ Иң-иң-иң...”Р.Батулла.* | Әсәрләрнең төп уен ачыклау. Шигырьләрне яттан сөйләү. Әсәрләрне рольләргә бүлеп уку. Р.Валиева. “Күбәләк | 20.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | *Җ.Тәрҗеманов “ табигать китабы”* | һәмКырмыска”әсәрләренең төп уен билгеләү. | | |
| 32 | Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен. *“Супермалай” Л.Лерон , “Хикмәтле сүз” Ф.Яруллин ”Дуслык” “Светофорның өч күзе” “Ш.Галиев* | Бүлек исеме белән танышу.Тема буенча китаплар күргәзмәсе оештыру.. Хикәядәге геройларга мөнәсәбәтне,карашны белдерү. И.Тукар, Л. Лерон хикәяләре . Хикәяләрнең темасын ачыклау. | | |
| 33 | Яз килә,яз көлә. Г. *Тукай. “Яз” Г. Зәйнашева. “Әниләр бәйрәме” Л. Лерон. “Апрель ае”.* **Сабантуй бәйрәме. Алексеевскида Сабантуй бәйрәменең үзенчәлекләре.** Үткәннәрне кабатлау | Бүлек исеме белән танышу.<br>Бүлек эчтәлеген кузаллау.<br>Тема буенча китап күргәзмәсе оештыру.<br>. Үтелгән әсәрләрне, авторларны барлау. Сабантуй бәйрәме турында сөйләшү. | | |

**Ятлау өчен әсәрләр**

1. Габдулла Тукай “Әлифба”, “Гали белән кәҗә”
2. Санамышлар.
3. Гөлшат Зәйнашева.”Бер атнада ничә көн?”
4. Резеда Вәлиева. Әниләр бәйрәме.